**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2019 № 646

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 июнендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 424 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 июнендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 424 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6 пунктының 4 пунктчасында «проект документларының» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен дә кертеп)» сүзләрен өстәргә;

3.4.1 пунктының 4 пунктчасында «проект документларының» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9

өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен дә кертеп)» сүзләрен өстәргә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин